| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.05.2024 п.г.т Алексеевское № 177

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 01.09.2021ел, №318 «Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм Бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең Административ регламентларын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең республика органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчен югалтуын тану хакында» 28.02.2022 ел, № 175 карарына таянып

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 01.09.2021ел, №318 «Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм Бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең Административ регламентларын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- регламентның атамасында «Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге» сүзен «Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт, туризм һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча профилактика бүлеге» сүзләре белән алыштырырга;

- 4 пунктта «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге Е.Г. Салюков» сүзләрен «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт, туризм һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча профилактика бүлеге Р. Б. Сөләйманов» сүзләре белән алыштырырга.

1.1. спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентында (1 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

-2.4.1 пунктында. «спорт разряды бирү документлар комплекты белән гариза теркәлгәннән соң биш эш көне эчендә башкарыла» сүзен «спорт разряды бирү документлар комплекты белән гариза теркәлгәннән соң уналты эш көне эчендә башкарыла» сүзләренә алыштырырга,

-2.5.1 пунктында «б» пунктчасында «судьялар коллегиясенең составы һәм квалификациясе турында белешмәнең күчермәсе. судьялар коллегиясе рәисе (баш судья) һәм ярышларны үткәрүче оешма тарафыннан вәкаләтләнгән зат тарафыннан имзаланган СМК ның Спорт разрядларын бирү өчен, «беренче спорт разряды», «икенче спорт разряды», «өченче спорт разряды» (халыкара ярышлардан тыш)» сүзләрен «судьялар коллегиясенең составы һәм квалификациясе турында белешмәнең күчермәсен ,судьялар коллегиясе рәисе (баш судья) тарафыннан имзаланган (халыкара ярышлардан тыш)» сүзләре белән алыштырырга;

2.5.1 пунктын «з» пунктчасы белән тулыландырырга «спорт судьясының тиешле спорт төре буенча халыкара категориясе булуын һәм халыкара спорт федерациясенең календарь планына кертелмәгән халыкара ярышлар өчен - СМК спорт разрядын бирү өчен халыкара ярышлар өчен «бөтенроссия категориясендәге спорт судьясы» таныклыкларының таныкланган рус теленә тәрҗемә ителгән күчермәләрен. Күрсәтелгән документларның күчермәләре спортчы нормаларны, таләпләрне һәм шартларны үтәгән ярышларда хөкемдарлык итүне гамәлгә ашыручы судьялар коллегиясе составына кертелгән спорт судьяларына тапшырыла: тиешле халыкара спорт федерациясенең календарь планына кертелмәгән халыкара ярышлар өчен – 5, калган ярышлар өчен – 3»;

1.2. спорт судьясының квалификация категориясен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентында (2 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

-2.4.1 пункты «спорт судьясы квалификация категориясен бирү документлар комплекты белән гариза теркәлгәннән соң биш эш көне эчендә башкарыла» сүзләрен «спорт судьясы квалификация категориясен бирү документлар комплекты белән гариза теркәлгәннән соң уналты эш көне эчендә башкарыла» сүзләренә алыштырырга;

2. Әлеге карарны «Интернет» челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт, туризм һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча профилактика Бүлеге башлыгы Р.Б. Сөләймановка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **М.Р. Гайсин**